**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘЛМӘНДӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

3 сентябрь 2019 ел №152

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Әлмәндәр авыл җирлеге Генераль планына үзгәрешләр кертү турында**

1998 елның 24 июнендәге "Җитештерү һәм куллану калдыклары турында" 89-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Әлмәндәр авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Әлмәндәр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Әлмәндәр авыл җирлеге генераль планын раслау турында» 2019 елның 9 апрелендәге 136 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Әлмәндәр авыл җирлеге Генераль планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2.9.8 пунктта алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«Калдыклар белән эш итү өлкәсендә территориаль схема нигезләмәләре буенча, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итүнең федераль схемасы нигезендә, калдыкларны чыгару шәһәр тибындагы Апас поселогы полигонына калдыкларны чыгару оештырылылып, Югары Ослан муниципаль районында урнашкан муниципальара тармак комплексына илтеләчәк.»;

б) 7.3 пунктта илле бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

« - шәһәр тибындагы Апас поселокның гамәлдәге каты коммуналь калдыклар полигонына каты коммуналь калдыкларны чыгаруны оештыру, Югары Ослан муниципаль районындагы муниципальара тармак комплексына (калдыклар белән эш итү өлкәсендәге территориаль схема нигезендә, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итүнең федераль схемасы белән) илтү»".

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Әлмәндәр авыл җирлеге башлыгы** **Р. Х. Җәләлиев**